КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 27 апрель г.Казань № 532

Татарстан Республикасында мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендә стартаплар реестрын булдыру һәм алып бару тәртибе турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендә эшчәнлек алып баручы Россия оешмаларына дәүләт аккредитациясе турында нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 30 сентябрендәге 1729 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасында мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендә стартаплар реестрын булдыру һәм алып бару тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгын Татарстан Республикасын мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендә стартаплар реестрын булдыру һәм алып бару буенча вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2019 ел, 1 ноябрь, 997 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 17 февраль, 116 нчы, 2020 ел, 21 сентябрь, 848 нче, 2020 ел, 23 октябрь, 953 нче, 2021 ел, 16 август, 725 нче, 2023 ел, 20 февраль, 166 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы турында нигезләмәгә, 3.3 пунктка түбәндәге эчтәлеклее 3.3.2.22 пунктча өстәп, үзгәреш кертергә:

«3.3.2.22. Татарстан Республикасында мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендә стартаплар реестрын булдыру һәм алып баруны гамәлгә ашыра;».

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасында мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендә стартаплар реестрын булдыру һәм алып бару тәртибенә кушымта

Форма

Татарстан Республикасында мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендә стартаплар реестры

| Т/с | Оешма исеме | ИНН | ЕГРЮЛ теркәү датасы | Икътисадый эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторы (ОКВЭД) | Оешма булдырылганнан соң алынган керем күләме | Оешма сайтының адресы (булган очракта) | Элемтә мәгълүматлары: телефон, почта | Оешма җитәкчесенең Ф.Ис.Ат.ис. (соңгысы – булганда) | Оешманың адресы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | | | | | |
| 2. | | | | | | | | | |
| 3. | | | | | | | | | |

___________________________________________